| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ОЛЫ МЕМИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

27.01.2022 с. Большие Меми № 3

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлегендә 2022 елга җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Җирләү һәм җирләү эше турында» 12.01.1996 ел, № 8-ФЗ Федераль законның 9 статьясындагы 3 пункты һәм 12 статьясындагы 3 пункты нигезендә, «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте карары проекты буенча, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 18.05.2007 ел, №196 һәм «Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты мәсьәләләре» 15.06.2010 ел, № 468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Олы Меми авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6964 сум 68 тиен күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2022 елның 1 февраленнән 1, 2 кушымталар нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Борнаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г.А. Фомина

Татарстан Республикасы Югары Ослан
муниципаль районы Олы Меми авыл
җирлеге Башкарма комитетының
27.01.2022 ел 3 карарына
1 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлегендә 2022нче елның 1нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3601,25 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка озату | 1116,65 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2246,78 |
| Барлыгы | 6964,68 |

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге Башкарма комитетының 27.01.2022 ел 3 карарына
2 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлегендә 2022нче елның 1нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәетне кәфенләү | 666,35 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле әйберләрне бирү һәм китерү | 2934,90 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка илтү | 1116,65 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2246,78 |
| Барлыгы | 6964,68 |